ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**“ 28 ” гыйнвар 2017 ел** **№ 92**

**Арча муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача айлык эш хакы һәм Арча муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең уртача айлык эш хакы чагыштырмасының чик дәрәҗәсен билгеләү турында**

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 3 июлендәге 347-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 144, 145, 349.5 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 26 ноябрендәге 2190-р номерлы карары белән расланган 2012-2018 елларга дәүләт (муниципаль) учреждениеләрендә хезмәт өчен түләү системасын этаплап камилләштерү программасы нигезендә,муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш хисапчыларының хезмәт хакын түләү шартларын тәртипкә салу максатларында, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Арча муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарлары һәм баш бухгалтерларының уртача айлык хезмәт хакы һәм муниципаль учреждениеләр, предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача айлык хезмәт хакы чагыштырмасының чик дәрәҗәсен 1 дән 8 гә кадәр билгеләргә.

2.Арча муниципаль районы предприятиеләре, җитәкчеләре, аларның урынбасарлары һәм баш хисапчылары өчен хезмәт хакы түләү шартлары әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән уртача айлык хезмәт хакы күләмнәренең чик дәрәҗәсен исәпкә алмыйча билгеләнә торган муниципаль учреждениеләр, предприятиеләр исемлеген расларга.

3.Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru( яки Арча муниципаль районының рәсми сайтында басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җитәкче урынбасары Р.И. Гарифҗановка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә.Галимуллин

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
«28»гыйнвар 2017 ел №92 карары белән
расланды
**РАСЛАНДЫ**

**Арча муниципаль районы предприятиеләре, җитәкчеләре, аларның урынбасарлары һәм баш хисапчылары өчен хезмәт хакы түләү шартлары әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән уртача айлык хезмәт хакы күләмнәренең чик дәрәҗәсен исәпкә алмыйча билгеләнә торган муниципаль учреждениеләр, предприятиеләр исемлеге**

1) Арча муниципаль районының "Капиталь төзелеш һәм архитектура бүлеге" муниципаль автоном учреждениесе;
2) "Арча муниципаль районы Гражданнар оборонасы идарәсе" муниципаль казна учреждениесе.